**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2017 ел, 13 апрель № 224

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе турында» 2012 ел, 2 июль, 575 нче карары белән расланган Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе турында» 2012 ел, 2 июль, 575 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 27 октябрь, 909 нчы; 2013 ел, 25 март, 200 нче; 2013 ел, 14 декабрь, 990 нчы; 2014 ел, 25 ноябрь, 912 нче; 2015 ел, 16 июль, 522 нче; 2015 ел, 25 декабрь, 985 нче; 2016 ел, 31 декабрь, 1084 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Комиссия составыннан Е.И.Согринаны чыгарырга;

Комиссия составына Зарипов Марат Наил улын – Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсе җитәкчесенең беренче урынбасары (килешү буенча);

Комиссиия әгъзасы Р.Р.Шәймурзин вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җәзалар үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча җинаять-үтәтү инспекциясе» федераль казна учреждениесе башлыгы.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин